ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

26 04 2021 г. № 25

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү һәм аларда булган мәгълүматларны тикшерү тәртибен раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү һәм аларда булган мәгълүматларны тикшерү тәртибен расларга (кушымта).

2. Түбән Кама муниципаль районы Башлыгының «Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе турында» 2009 елның 16 октябрендәге 102 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе А.Р. Сафинга йөкләргә.

А.Р.Метшин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044807

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгының
2021 елның 26 нчы апрель
25 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

## Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү һәм аларда булган мәгълүматларны тикшерү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү һәм аларда булган мәгълүматларны тикшерү тәртибе (алга таба – тәртип) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип муниципаль хезмәткәрне коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкиленә хәбәр итү процедурасын, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеген, кергән хәбәрнамәләрне теркәү тәртибен, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыруны күздә тота.

1.3. Әлеге тәртип, мондый җирлекләргә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән тәртиптә мондый җирлекләргә муниципаль хезмәт өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итү вәкаләтләрен тапшырган очракта, Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә, шул исәптән Түбән Кама муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең муниципаль хезмәткәрләренә кагыла.

1.4. Муниципаль хезмәткәрне коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итүнең барлык очраклары турында, әлеге фактлар буенча тикшерү уздырылган булу яки уздыру очракларыннан тыш, яллаучы вәкиленә хәбәр итү бурычы муниципаль хезмәткәргә йөкләнә.

1.5. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә каралган һәм әлеге Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи бурычларны муниципаль хезмәткәр тарафыннан үтәмәү аны муниципаль хезмәттән азат итүгә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр җаваплылыкка тартуга китерә.

1.6. Коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатыннан, хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле башка муниципаль хезмәткәрләргә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү факты турында, башка муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупцион хокук бозулар кылу фактлары турында, мәгълүмат тапшырмау яисә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат бирү турында аңа билгеле булган муниципаль хезмәткәр бу хакта Тәртип нигезендә яллаучы вәкиленә хәбәр итәргә хокуклы.

## II. Яллаучы вәкиленә хәбәр итү тәртибе

2.1. Муниципаль хезмәткәр нинди дә булса коррупцион хокук бозу турында тәкъдим алган очракта, ул, мөрәҗәгать итү көненнән соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча (ял көннәреннән һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш), яллаучы вәкиленә әлеге факт турында әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

Муниципаль хезмәткәр командировкада, чираттагы ялда, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка нигезләр буенча хезмәт итү урыныннан читтә булган очракта, ул өч көн эчендә теләсә кайсы элемтә чарасы (телефонограмма, заказлы хат, электрон почта һ.б.) ярдәмендә коррупциячел хокук бозу кылуга тартылу факты турында хәбәр итәргә, ә хезмәт урынына килгәч, тиешле хәбәрнамәне билгеләнгән формада язмача бирергә тиеш.

2.2. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәгә муниципаль хезмәткәрне коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итүнең шартларын раслаучы материаллар теркәлә ала.

2.3. Прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына муниципаль хезмәткәр аны коррупцион хокук бозу кылуга тарту фактлары турында хәбәр иткән очракта, ул бу хакта яллаучыга (эш бирүчегә) хәбәр итәргә тиеш.

## III. Хәбәрнамәдә булган мәгълүматлар исемлеге

3. 1. Хәбәрнамәдә муниципаль хезмәткәр күрсәтә:

- фамилиясе, исеме, атасының исеме, биләгән вазыйфасы, элемтә өчен телефоннар;
- коррупцион хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында, хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле муниципаль хезмәткәргә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү очраклары турында билгеле булган хәлләрне тасвирлау (датасы, урыны, вакыты, башка шартлар). Әгәр хәбәрнамә әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәткәр тарафыннан җибәрелә икән, коррупцион хокук бозулар кылуга тартылучы хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелә;
- муниципаль хезмәткәр мөрәҗәгать иткән затларның үтенече буенча башкарырга тиешле коррупцион хокук бозулар турында тулы мәгълүмат;
- коррупцион хокук бозуга этәргән физик (юридик) зат турында барлык билгеле булган мәгълүматлар;

- коррупцион хокук бозуга тартылу ысулы һәм шартлары, шулай ук затның коррупцион хокук бозу турында тәкъдимен кабул итүдән баш тарту (риза булу) турында мәгълүмат.

3.2. Хәбәрнамәне тутыру датасын күрсәтеп, хәбәрнамә муниципаль хезмәткәр тарафыннан шәхсән имзаланырга тиеш.

## IV. Хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе

4.1. Түбән Кама муниципаль районы Советының коррупциягә каршы эш бүлеге (алга таба - коррупциягә каршы эш бүлеге) коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында муниципаль хезмәткәрләрдән кергән хәбәрнамәләрне кабул итә, терки һәм исәпкә ала, шулай ук коррупцион хокук бозу кылуга тартылучы муниципаль хезмәткәрдән алынган шәхси мәгълүматларның конфиденциальлеген һәм сакланышын тәэмин итә.

4.2. Кергән хәбәрнамә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамәләрне исәпкә алу журналында теркәлә. Журналга түбәндәге мәгълүмат кертелә:

- теркәү номеры;
- хәбәрнамәне теркәү датасы;
- хәбәрнамәне имзалаган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, элемтә өчен телефоны;
- хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге;
- хәбәрнамәне кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы.

4.3. Кергән хәбәрнамәнең беренче нөсхәсе теркәлгән көнне карау нәтиҗәләре буенча хәбәрнамәдә булган мәгълүматны тикшерүне оештыру турында карар кабул итүче яллаучы вәкиленә карауга тапшырыла.

Теркәү номеры, датасы һәм кабул итүче затның имзасы булган икенче нөсхә, мәгълүматларны кабул итү һәм теркәү өчен, муниципаль хезмәткәргә бирелә.

## V. Хәбәрнамәдә булган мәгълүматны тикшерүне оештыру мәсьәләләре

5.1. Хәбәрнамәдә булган мәгълүматларны тикшерүне оештыру Түбән Кама муниципаль районының хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе (алга таба - Комиссия) тарафыннан үткәрелә.

5.2. Тикшерү барышында, хәбәрнамә җибәргән муниципаль хезмәткәрдән язма аңлатмалар алына, хезмәткәрне коррупциячел гамәлләр кылуга этәргән шартлар билгеләнә, компетенция кысаларында муниципаль хезмәткәр тапшырган мәгълүматны һәрьяклап карау өчен кирәкле башка чаралар гамәлгә ашырыла.

5.3. Хәбәрнамәдә булган мәгълүматларны тикшерү яллаучы вәкиле тарафыннан аны үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң ундүрт эш көне эчендә үткәрелә.

5.4. Тикшерү барышында алынган материаллар Комиссия утырышында Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының 2018 елның 29 июнендәге 50 номерлы карары белән каралган тәртиптә һәм срокларда карала.

5.5. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия карары белән хәбәрнамә яллаучы вәкиленә тиешле мәгълүматны прокуратура органнарына яки башка хокук саклау органнарына җибәрү өчен тапшырыла.

Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибенә
1 нче кушымта

(Форма)

______________________________________
(муниципаль хезмәткәрне
______________________________________
яллаучы
______________________________________
вәкиле исеме)
____________________________
(Ф.И.А., вазыйфасы, телефон)
______________________________________
______________________________________
______________

Муниципаль хезмәткәрне коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү факты турында
хәбәрнамә

Хәбәр итәм:

1) ________________________________________________________________
(коррупцион хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында,
__________________________________________________________________
хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле
__________________________________________________________________
муниципаль хезмәткәргә нинди дә булса затларның
__________________________________________________________________
мөрәҗәгать итү очраклары турында
__________________________________________________________________
билгеле булган хәлләрне тасвирлау
__________________________________________________________________
(датасы, урыны, вакыты, башка шартлар)
_________________________________________________________________,

2) ________________________________________________________________
(муниципаль хезмәткәр мөрәҗәгать иткән затларның үтенече буенча

___________________________________________________________________________
башкарырга тиешле коррупцион хокук бозулар турында
___________________________________________________________________________
тулы мәгълүмат)
__________________________________________________________________________,

3) ________________________________________________________________________
(коррупцион хокук бозуга этәргән физик (юридик) зат турында
___________________________________________________________________________
барлык билгеле булган мәгълүматлар)
___________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________,

4) ________________________________________________________________________
(коррупциячел хокук бозуга тарту ысулы һәм шартлары
___________________________________________________________________________
(сатып алу, янау, алдау һ. б.), шулай ук коррупциячел хокук бозуны кылу турында
___________________________________________________________________________
затның тәкъдимен кабул итүдән баш тарту
__________________________________________________________________________,
турында (ризалыгы турында) мәгълүмат)

_______________________________________
(дата, имза, инициаллары һәм фамилиясе)

Хәбәрнамә теркәү
журналында теркәлгән
«___» _____________20___ел. №____
_____________________________________
(Ф.И.А., җаваплы затның вазыйфасы)

Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибенә
2 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрен коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамәләрне теркәү журналы

<table>
<tr><td rowspan="2">т/с</td><td rowspan="2">Теркәү датасы</td><td colspan="3">Хәбәрнамә җибәргән муниципаль хезмәткәр турында мәгълүмат</td><td rowspan="2">Хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге</td><td rowspan="2">Хәбәрнамә кабул иткән затның Ф.И.А., имзасы</td></tr>
<tr><td>Ф.И.А.</td><td>вазыйфасы</td><td>Элемтә өчен телефон номеры</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>